Кыш vзенен аклыгы, сафлыгы белән kvнелгә якын, vзенчә матурлыгы белән vтеп бара. Чын кышны, билгеле инде, урманда гына тоярга була. Ә кырлар, яз житкәнче ял итәргә уйлап, ап-ак юрганга торенәләр дә тыныч кына тирән йокыга талалар. Анда ап-ак кардан башка берни дә kvреп булмый. Урманда песнәкләрнен һәм саесканнын агачтан агачка сикереп йорve кышкы урманга азмы-kvпме жанлылык орә. Ап-ак тvшәк остендәге жәнлек әзләре дә урманнын ботенләй vк йоклап ятмавын kvрсәтә. Салкын коннәрдә агачлар бәс белән каплана. Әйтерсен агачларны vтә kvренмәле ап-ак ефәк белән чорнап чыкканнар. Ботен доньяда матурлык, аклык, сихри тынлык.

Урман. Сихри донья. Шундый урманга, урнаштырылган традиция буенча, ел саен Кадошкино районы Латышовка авылы мәктәбе укытучылары белән укучылары баралар. Быел да шулай сәяхәткә чыккан иделәр. Бер мәлгә кышкы урман балалар тавышы белән тулды, әкияттәге тосле кар остендә учак чатырдады, казандагы су шапылдап кайнады һәм пешкән пилмәннәр исе урманны анкытты. Һәрбер кышкы агач, урман жәнлекләре һәм кошлар бу тәмле исне сизделәр тосле. Бик гади һәм шул ук вакытта ничектер сихерле дә. Традициягә кергән бу сәяхәт башы 2000нче елда башлана. Утыз елдан артык Латышовка мәктәбендә тырышып чит тел (немецкий), рәсем һәм сызым (черчение) предметларыннан белем биргән, мәктәп һәм Латышовка мәдәни йортындагы стендларны, әдәби газеталарны, район бәйрәмнәрен тиешле дәрәжәдә матурлап килгән Клара Рафик кызы Резакова, бу елда унберенче сыйныфлыларнын житәкчесе буларак, кышкы урманга «сихерле пилмәнгә» барырга дигән тәгъдим белән чыга. Мондый сәяхәттә булмаганнарнын бик тә исләре китә: кышын нинди урман да һәм нинди инде ул сихерле пилмән...

[redacted]